| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЕЛАУР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Елаур ав. | КАРАР |
| «22» октябрь 2019 ел | | № 4 |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 6 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Бакча урамы, 5 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында Бакча урамы буенча1-38нче, Кыр урамы буенча 2-29нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслеген күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре).

Октябрина т.п. су алу өчен пирс әзерләү ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

| | |
|---|---|
| « РИЗА» | «КАРШЫ» |

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында

бастырып чыгарырга,  Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Октябрина торак пункты мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охототникова